УДК 030

***Л.Т. Нигъмәтҗанова***

# ТАТАРСТАНДА ФИЗКУЛЬТУРА-СПОРТ ХӘРӘКӘТЕН ӨЙРӘНҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК «ТАТАРСТАНГА – 100 ЕЛ: РӘСЕМЛЕ ЭНЦИКЛОПЕДИК ЯЗМАЛАР» КИТАБЫ

В статье рассматривается возникновение и процесс развития спортивного движения в Республике Татарстан, описанные в книге «Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки»; освещена история ведущих спортивных клубов республики. В этом издании наиболее полно и достоверно представлена история развития спорта на территории Республики Татарстан, начиная с периода становления ТАССР и заканчивая современным положением в области спорта и физического воспитания подрастающего поколения. В книге представлен богатый фактический материал, размещено множество иллюстраций, относящихся к рассматриваемому периоду. На страницах очерков раскрываются важнейшие вехи истории Татарстана.

**Ключевые слова:** спортивное движение, физкультурное общество, массовый спорт, здоровый образ жизни, энциклопедические очерки.

The article discusses the emergence and development of the sports movement in the Republic of Tatarstan, described in the book «Tatarstan – 100 years: illustrated encyclopedic essays»; highlights the history of the leading sports clubs of the Republic. In this publication the history of the development of sports on the territory of the Republic of Tatarstan is presented most fully and reliably from the period of the formation of the Tatarstan Autonomous Soviet Socialist Republic to the current situation in sport and physical education of the younger generation. The book contains rich factual material, contains many illustrations related to the period under review. The pages of essays reveal the most important milestones in the history of Tatarstan.

**Keywords:** sports movement, physical culture society, mass sports, healthy lifestyle, encyclopedic essays.

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы 1920 елдан 2020 елга кадәр республиканың иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышын чагылдырган рәсемле энциклопедик язмалар әзерләде. «Татарстанга – 100 ел»: рәсемле энциклопедик язмалар» китабында [Татарстанга – 100 ел, 2019] укучыга Татарстан тарихы, дәүләт төзелешенең мөһим сәхифәләре, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф, мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары, сәламәтлек саклау һәм спорт үсешенең төп этаплары сурәтләнгән бай фактик һәм иллюстратив материал тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы тарафыннан әзерләнгән «Татарстанга – 100 ел» рәсемле энциклопедик язмалар

1990 елларда ук Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты М.Х. Хәсәнов җитәкчелегендә эшләнә башлаган энциклопедик басмалар сериясен дәвам итә.

Китап Татарстан Республикасының 100 еллыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 декабрендәге «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүенең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планын раслау турында» 1020 нче карары нигезендә нәшер ителә.

Язмаларда укучы 1920 елдан 2020 елга кадәр Татарстан тарихы, дәүләт төзелеше, республиканың иҗтимагый-сәяси, икътисади тормышы, фән, мәгариф һәм этномәдәни үсешенең төп этаплары турында мәгълүмат таба ала.

Китапның кереш өлешендә Татарстанның дәүләтчелек тарихы, 1920 елда Татарстан АССР төзелү, республика үсешендәге сәяси, социаль-икътисади һәм этномәдәни процесслар турында материал тупланган.

Китап кеше тормышының төрле өлкәләренә багышланган тугыз өлештән тора. *Беренче* өлешендә Татарстан Республикасы сәяси тарихының мөһим сәхифәләре, республиканың борынгы кабиләләрдән алып бүгенге көнгә кадәрге күп гасырлык тарихы яктыртыла. *Икенче* өлешендә дәүләт хакимияте һәм идарә органнары, Татарстанда дәүләт хакимияте югары органнары системасы формалашу, бүләкләр, исемнәр һәм премияләр турында тәфсилләп бәян ителә. *Өченче* өлеше Татарстанның административ-территориаль бүленешенә багышлана, республика районнары составына кергән барлык торак пунктлар тасвирлана. Татарстан – Россия Федерациясенең күпмилләтле төбәкләреннән берсе. Аның территориясендә үз гореф-гадәтләре һәм дине булган 170 тән артык халык вәкиле яши. Авторлар коллективы Татарстанның этномәдәни үсешенә аерым игътибар бирәләр, китап битләрендә республикада яшәүче халыклар, аларның дине һәм бәйрәмнәре белән тулырак танышып була. Аларның таралу тарихы, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре *дүртенче* өлештә җентекләп бәян ителә. Татарстан Республикасы – мәгариф һәм фән югары үсешкә ирешкән төбәк. Биредә гомуми белем, һөнәри һәм югары уку йортлары челтәре үсеш алган. Күп гасырлык халык мәгарифе турында *бишенче* өлешендә бәян ителә. *Алтынчы* өлеше Татарстан Республикасы икътисадына, сәнәгатенә һәм авыл хуҗалыгына багышланган. Татарстанның бай мәдәни мирасы һәм сәнгате турында китапның *җиденче* өлешендә бәян ителә. *Сигезенче* өлештә Татарстан Республикасының барлык массакүләм мәгълүмат чаралары тәкъдим ителгән, китап басу эше барлыкка килү, шулай ук аның хәзерге торышы тасвирланган. Китапның *тугызынчы* өлешендә сәламәтлек саклау һәм спорт үсешенең төп этаплары яктыртылган.

Шулай итеп, әлеге китапта чыганакларга таянып һәм тарихи нигездә киң хронологик кысаларда (1920–2020 еллар) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче төрле халыкларның тарихы,

мәдәнияте, гореф-гадәтләре, диннәре һәм хәзерге халәте буенча статистик һәм динамик күрсәткечләр китерелә. Архив документларына нигезләнеп, республиканың тарихи һәм икътисади үсеше контекстында татарларның бай тарихы һәм мәдәнияте торгызыла һәм өйрәнелә.

Әлеге язмалар институт тарафыннан 1990 елларда ук эшләнә башлаган энциклопедик басмалар сериясен дәвам итә [Татарский энциклопедический словарь, 1999; Татарская энциклопедия, 2002–2014; Республика Татарстан, 2010; Татарстан, 2013]. «Спорт һәм спорт объектлары» бүлегенең «Сәламәтлек саклау һәм спорт» өлешендә физкультура-спорт хәрәкәтенең барлыкка килүе һәм үсеше тасвирлана, бу исә Казан шәһәрендә XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында гамәлгә керә башлаган ирекле спорт җәмгыятьләре һәм берләшмәләре оешу белән бәйле. 1917 елгы инкыйлабтан соң спорт җәмгыятьләре оештыру процессы активлаша, алар Казанда гына түгел, ә республика районнарында да барлыкка килә. Республикадагы спорт хәрәкәтен 1919 елда оешкан Казан губерна хәрби комиссариаты һәм Казан губерна спорт берлеге каршындагы физик тәрбия һәм спорт бүлеге җитәкли. 1921 елда Казанда оештырылган Бөтентатар спорт берлеге барлык спорт җәмгыятьләрен, секцияләрне һәм түгәрәкләрне берләштерә. 1920–1930 елларда ук күпсанлы физкультура җәмгыятьләре («Татпечать», «Железнодорожник», «Флорида», Үзәк физик тәрбия йорты, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте, «Спартак» һ.б.) оештырыла, аларда җиңел һәм авыр атлетика, йөзү, бокс, көрәш, шахмат, шашка, фехтование һ.б. секцияләр эшли.

Республиканың аерым спортчылары һәм җыелма командалары илнең зур ярышларында призлар яулыйлар. Бу елларда ТАССР Сәламәтлек саклау һәм Мәгариф Халык комиссариатлары каршында оештырылган физик тәрбия бүлекләрендә беренче һәм икенче баскыч мәктәпләрдә физкультура дәресләре программалары эшләнә башлый, бу исә Татарстанда массачыл физкультура һәм спорт хәрәкәтенең үсешенә китерә.

1930 еллар башында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) физкультура комплексы һәм Бердәм Бөтенсоюз спорт классификациясе кертелү физкультура хәрәкәтенең актив үсешенә китерә, бу исә оештыру һәм җитәкчелек итүнең гадәти формаларын үзгәртүгә сәбәп була. Нәтиҗәдә, 1935 елда бөтен ил буенча үз уставлары, эмблемалары, әгъзалык билгеләре һәм спорт формалары булган ирекле спорт җәмгыятьләре (ДСО) барлыкка килә. Авыллардагы физкультура хәрәкәтендә дә шул ук хәл күзәтелә: бу чорда ул зур тизлек белән үсә башлый. Спорт оешмаларын квалификацияле белгечләр белән Казан физик тәрбия техникумы һәм Казан педагогика училищесенең физик тәрбия бүлеге тәэмин итә. Спортның техник төрләре үсешенә 1927 елда оештырылган Оборонага, авиация һәм химия төзелешенә ярдәм ирекле җәмгыяте (ОСОАВИАХИМ, хәзер «Татарстан Республикасы армия, авиация һәм флотка ярдәм

ирекле җәмгыяте» (ДОСААФ) төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе) зур өлеш кертә.

Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР физик тәрбия һәм спорт оешмаларының эшчәнлеге Кызыл Армия резервларын әзерләү һәм яраланган хәрбиләрнең сәламәтлеген кайтару бурычларын хәл итүгә юнәлтелә. Күпсанлы хәрби-өйрәнү пунктлары җитәкчеләре һәм инструкторлары, кул көрәше, чаңгычылар, дәвалау физкультурасы инструкторлары әзерләнә.

Сугыштан соңгы елларда «Смена» һәм «Хезмәт резервлары» балалар-яшүсмерләр ирекле спорт җәмгыятьләре булдырыла, физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны шактый арта. ТАССР спорт командалары һәм аерым спортчылар төрле спорт ярышларында зур уңышларга ирешәләр.

1980 елларда республикада спорт хәрәкәте яңа уңышлар яулый. 1980 еллар ахырында Татарстан илнең автономияле республикалары арасында беренче урынны били һәм союздаш республикалар арасында Эстония белән сигезенче урынны бүлешә. Үзгәртеп кору һәм аннан соңгы елларда илдәге спорт хәрәкәте үсеше тиешле дәрәҗәдә финансланмауга карамастан, 1990 еллар башына Татарстанда 1901 СССР спорт остасы, 68 халыкара класслы спорт остасы, 14 СССРның атказанган спорт остасы әзерләнә; СССРның атказанган тренеры исеменә – 8, РСФСРның атказанган тренеры исеменә 47 кеше лаек була.

XXI гасыр башында физик тәрбия һәм спорт үсеше республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстанда спорт төрләре буенча бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышлары: тимераякта фигуралы шуу, җиңел атлетика буенча Россия чемпионатлары, 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты, футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары, авиаузышлар буенча дөнья чемпионаты этабы һ.б. уздыру физик тәрбия һәм спорт үсешен активлаштыручы факторларга әвереләләр. Күпсанлы спорт объектлары төзелә башлый: «Баскет-холл», «Татнефть Арена» боз спорт сарае, «Казан Арена» универсаль футбол стадионы (хәзер «Ак Барс Арена»), Спортның су төрләре сарае, Чирәмдәге хоккей үзәге, «Казан» халыкара ат спорты комплексы, «КАИ Олимп» мәдәни-спорт комплексы, «Ак Барс» көрәш сарае, Казан теннис академиясе һ.б. ТР Спорт министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2019 ел башында республикада 288,3 мең кеше сыйдырышлы 11 013 спорт корылмасы эшли. Авыл җирлегендә физкультура-спорт хәрәкәтен үстерүгә зур игътибар бирелә.

2015 елда Казанда балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт-адаптив мәктәбен булдыру адаптив физик тәрбия һәм спортны үстерүгә көчле этәргеч була. Хәзерге вакытта мәктәптә чукраклар (ирекле көрәш, керлинг, йөзү, җиңел атлетика) һәм сукырлар (йөзү, җиңел атлетика), терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар (академик ишү, бочче, йөзү, чаңгы ярышлары, җиңел атлетика), интеллектуаль

тайпылышлары булган затлар өчен (җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү) спорт бүлекләре эшли.

Татарстан спортчыларының күпсанлы спорт төрләрендәге югары күрсәткечләре һәм казанышлары Татарстан – Россия Федерациясенең спорт төбәкләреннән берсе, дип сөйләргә мөмкинлек бирә.

«Әйдәп баручы спорт клублары» өлешендә предприятиеләрдә, уку йортларында беренче җәмгать физкультура-спорт оешмалары барлыкка килү тарихы тасвирлана. ВКП (б) Үзәк Комитетының 1948 елның 27 декабрендәге карары (спортсменнарга стипендия түләүне күздә тота) чыкканнан соң, зур спортның һөнәргә әйләнүе активлаша. Бу исә спорт белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнергә теләүчеләр санын арттыруга этәргеч була. Күп еллар элек булдырылган физик тәрбия коллективлары безнең көннәрдә спорт клублары статусын алалар: «Рубин» (1962 ел), М. Урицкий исемендәге (1963 ел), Я. Юдин исемендәге (1963 ел), В.Воровский исемендәге (1965 ел), «КАМАЗ» (1975 ел),«Электрон» (1987 ел) һ.б. Биредә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Татарстан Республикасында оешкан барлык спорт клублары турында тулы мәгълүмат бирелә.

«Халыкара ярышлар» өлешендә соңгы елларда Татарстан Республикасы территориясендә узган зур һәм әһәмиятле ярышлар һәм спорт чаралары, шул исәптән 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, 2015 елгы спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2017 елгы Конфедерацияләр кубогы, 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары турында сөйләнә.

«Спорт объектлары» өлешендә республикада, 1927 елгы «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте стадионы һәм ату тиры, Татарстан профсоюзлары советы стадионы һәм су станциясе төзелү тарихыннан башлап, заманча стадионнар («Ак Барс Арена»), спорт үзәкләре (Гимнастика үзәге), йөзү бассейннары (Спортның су төрләре сарае), яссы мәйданлы корылмалар («Казан» халыкара атспорты комплексы), ясалма бозлы ябык спорт объектлары («Татнефть Арена») төзелү тарихына кадәр яктыртыла.

«Татарстанга – 100 ел» китабында республика территориясендәге физик тәрбия һәм спорт җәмгыятьләренең актив һәм бөтен җирдә таралыш алганын раслаучы архив фоторәсемнәре һәм документлар урнаштырылган. Мәсәлән, 1928 елда 1 нче татар укчы полкының футбол командасы төшерелгән фоторәсем. Рәсемнәр сыйфатында Татарстан өчен генә түгел, ә, гомумән, Россия Федерациясе өчен дә әһәмияте булган заманча спорт корылмаларын; Казанда һәм башка шәһәрләрдә узган спорт чараларын; Татарстан Республикасындагы әйдәп баручы спорт клублары һәм командаларын, шулай ук шәхси зачеттагы казанышларны чагылдырган фотосурәтләр файдаланылган.

Шулай итеп, «Татарстанга – 100 ел» китабында ТАССР төзелү чорыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр Татарстан Республикасы

территориясендә спорт һәм спорт хәрәкәте үсеше тарихы киң һәм төгәл яктыртылган, дип әйтеп була.

**Әдәбият**

Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки. Казань: ОСП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2019. 600 с.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. 703с.

Татарская энциклопедия. В 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002–2014.

Республика Татарстан. Природа, история, экономика, культура, наука. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. 194 с.

Татарстан: Иллюстрированная энциклопедия. Казань: ГУ «Институт Татарской энциклопедии АН РТ», 2013. 816 с.

***Нигъмәтҗанова Лилия Тәлгать кызы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре.*